| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«21» март 2019 с. Тюлячи № 162

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 1 сентябрендәге 434 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында мәктәпкәчә белеем бирү (балалар бакчалары) төп гомуми белеем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы 2010 елның 27 июлендәге 210 номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 елның 10 мартындагы 1389/15 номерлы боерыгы белән расланган «Мәктәпкәчә белем бирү (балалар бакчалары) төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм кабул итү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең Административ регламенты якынча формасына үзгәрешләр кертү турында»гы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2018 елның 26 декабрендәге под-1975/18 номерлы боерыгы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 1 сентябрендәге 434 номерлы карары (2015 елның 30 декабрендәге 631 номерлы, 2016 елның 8 февралендәге 50 номерлы, 2017 елның 20 июлендәге 329 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү (балалар бакчалары) төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба-Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктта 3.3.4 пунктчага түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«Ташламаның гамәлдәге срогы чыкканнан соң, мөрәҗәгать итүчегә Оешмага чираттан тыш яки беренче чиратта кабул итү хокукын раслау мәҗбүри.»;

1.2. 3.4.3 пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Уку елы дәвамында буш урыннар булганда, Оешмаларны Административ регламентның 3 пунктында каралган тәртип нигезендә комплектлау үткәрелә.»;

1.3. 3.4.3 пунктчаның өченче абзацын төшереп калдырырга;

1.4. 3.4.5 пунктчаның алтынчы абзацында «5 эш көненнән дә артмаска» сүзләрен «бер эш көненнән дә артмаска» сүзләре белән алыштырырга;

1.5. 3.5.3 пунктчаның икенче абзацында «3 ай эчендә» сүзләрен «бер ай эчендә» сүзләренә алмаштырырга»;

1.6. 3.5.4 пунктчаның беренче абзацына түбәндәге эчтәлектәге җөмлә өстәргә:

«Кабул итү датасы мөрәҗәгать итүче җибәрүдән баш тарту турында мөрәҗәгать иткән көннән дә иртәрәк булмаган датага алыштырыла.»;

1.7. 3.5.5 пунктчаның беренче абзацында «Оешма җитәкчесе Системада гаризага«Килмәде» статусы бирә дигән сүзләрне «Гаризага Системада «Килмәде» статусы бирелә дигән сүзләр белән алмаштырырга»;

1.8. 3.5.6 пунктчада беренче абзацка түбәндәге эчтәлектәге җөмлә өстәргә:

«Расланган очракта, теләгән вакытка кабул итү датасы мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтүгә ихтыяҗ булуын раслаучы көннән дә иртәрәк булмаган вакытка үзгәртелә.»;

1.9. 3.5.9 пунктчаның беренче абзацына түбәндәге эчтәлектәге җөмлә өстәргә:

«Расланган очракта, теләгән вакытка кабул итү датасы мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтүгә ихтыяҗ булуын раслаучы көннән дә иртәрәк булмаган вакытка үзгәртелә.»;

1.10. 3.6 пунктчага түбәндәге эчтәлектәге җөмлә өстәргә:

«Әгәр мөрәҗәгать итүче Оешмага чиратсыз, беренче чиратта кабул ителә ала икән, гариза бирүчегә «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУнә ташламаны раслаучы документларны, шулай ук аларның күчермәләрен тапшырырга кирәк.»;

1.11. 3.6.1. пунктчага түбәндәге эчтәлектәге җөмлә өстәргә:

«Балаларны бер Оешмадан икенчесенә күчерү вакытында ташламага ия категорияле гражданнарның балалары Федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм башка законга кагылышлы норматив-хокукый актлар белән билгеләнгән ташламалардан файдалана.».

2. Әлеге карарны Теләче муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.Ә. Нурмөхәмәтовка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин